# КАРАР

## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Үзәк торак пунктының гражданнар җыены буенча

**2019 елның 1 декабре** **Үзәк поселогы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 30 ноябрендә һәм 1 декабрендә Үзәк торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Үзәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

-лампалар, урам яктырткычлары, электр җиһазлары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү;

- тример сатып алу;
- автоном генератор сатып алу;
- вак таш җәелгән урамнарга ямау ремонты (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)түбәндәге урамнарга: Ленин, Татарстан, Әүхәдиев, Хафизов, Дударь, Южная, Молодежная, Кәримов, Макаров, Тукай, зиратка керү юлы;
- юлларны кардан чистарту;
- ике тирән су насосы сатып алу;
- зиратка бер контейнер сатып алу, зиратка хуҗалык бинасы төзү.

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 713 кеше кертелгән;

җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 406 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

халык җыеннарында 406 катнашучы «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Үзәк торак пунктында гражданнар җыеннары булып узды, гражданнар җыеннарының нәтиҗәләре - дөрес.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлегенең Үзәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

-лампалар, урам яктырткычлары, электр җиһазлары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү;

- тример сатып алу;

- автоном генератор сатып алу;

- вак таш җәелгән урамнарга ямау ремонты (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү)түбәндәге урамнарга: Ленин, Татарстан, Әүхәдиев, Хафизов, Дударь, Южная, Молодежная, Кәримов, Макаров, Тукай, зиратка керү юлы;

- юлларны кардан чистарту;

- ике тирән су насосы сатып алу;

- каты калдыклар өчен зиратка бер контейнер сатып алу, зиратта хуҗалык бинасы төзү кабул ителгән.

3. Җыен нәтиҗәләре турында әлеге карарны, гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән Үзәк авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Үзәк авыл җирлеге Башлыгы: В. Н. Котников